МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.03.2024 Казан ш № 217

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
27.03.2024 ел, №217 боерыгы белән
расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан инвалид балаларга, инвалидларга пособиеләр, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 июлендәге 516 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 22.06.2017 №406, 07.05.2018 №349, 18.09.2018 №885, 24.06.2019 №493, 12.11.2019 №992, 25.02.2020 №119, 14.07.2020 №516, 16.10.2020 №735, 31.08.2021 №624, 17.08.2022 №787, 12.01.2023 №15, 24.03.2023 №216, 11.10.2023 №799, 01.02.2024 №67 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике яисә бердәнбер ата-анасын югалткан инвалид балаларга, инвалидларга пособиеләр, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен законлы вәкилләр яки билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле затлар тәкъдим итә ала.»;

2.6.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

пособие, субсидия, стипендия билгеләү турында гариза (алга таба – гариза), банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп:

әлеге Регламентка 1 - $5^1$ нче кушымталар нигезендә кәгазь документ формасында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә туры китереп имзаланган электрон рәвештә (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон формасына кертү юлы белән тутырыла);

Укыган чорда ата-анасының икесен дә яки бердәнбер ата-ананы югалткан затлар чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән ата-ананың үлеме турындагы документ күчермәсен һәм аның нотариаль яктан таныкланган рус теленә тәрҗемәсен тапшыралар.

Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар (шул исәптән акыл ягыннан артта калуның төрле формалары булган) исәбендәге затлар «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 42 статьясының 5 өлеше нигезендә оештырылган психологик-медик-педагогик комиссиясе бәяләмәсе күчермәсен тапшыралар.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гариза почта аша җибәрелгән очракта, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән тыш) нотариус яки документ оригиналын биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында http://mtsz.tatarstan.ru урнаштырылган.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аны мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

Гаризаны һәм документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша, җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта) аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә БИАС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 14 апрелендәге 231 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.06.2017 №416, 07.05.2018 №348, 15.05.2018 №365, 18.09.2018 №858, 24.06.2019 №494, 11.11.2019 №978, 01.06.2020 №380, 09.10.2020 №718, 04.06.2021 №395, 25.10.2021 №784, 15.04.2022 №281, 02.11.2022 №977, 10.01.2024 №4 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

гражданинның амбулатор гемодиализ процедураларын узу датасы, махсуслаштырылган онкологик ярдәм күрсәтүче медицина оешмасында дәвалану чоры турында (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгыннан);

шәхси счетның иминият номеры турында( Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан);

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

мөрәҗәгать итүче яшәгән урыннан мөрәҗәгать итүче яшәгән Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) җирле администрациясе урнашкан урынга кадәр ара турында (җирле үзидарә органнарыннан).

Мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турындагы белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә алына.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.»;

3.4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, сорала торган белешмәләрнең исемлеге:

1) амбулатор гемодиализ процедураларын үтү датасы, гражданинның махсус онкологик ярдәм күрсәтүче медицина оешмасында дәвалану вакыты турында мәгълүмат. Гарызнамә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрелә;

2) шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр. Гарызнамә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

3) яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәү исәбе турында мәгълүматлар. Гарызнамә Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

5) мөрәҗәгать итүче яшәгән урыннан мөрәҗәгать итүче яшәгән Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) җирле администрациясе урнашкан урынга кадәр ара турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан).

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

1 нче кушымтада «Татарстан Республикасында турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә амбулатор гемодиализ буенча яшәү урынына һәм кирегә таба» сүзләрен «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә амбулатор гемодиализ узу урынына һәм кире яшәү урынына» сүзләре белән алмаштырырга.